КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 26 май г.Казань № б-1061

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 июнь, б-1214 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, б-2273 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең ел саен үткәрелә торган Спартакиадасын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составында:

Борһанов Рафис Тимерхан улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)»;

Гарипов Илнур Мәхмүт улын вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы, оештыру комитеты урынбасары (килешү буенча)»;

Гаффаров Рөстәм Гыйльфан улын вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең ел саен үткәрелә торган Спартакиадасын әзерләү һәм уздыру турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

3.2 һәм 3.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.2. Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, башкарма хакимият федераль органнарының территориаль

органнары командалары өчен җитәкчеләрнең яки аларның урынбасарларының уен беркетмәсе нигезендә спортның уен төрләрендә (баскетбол, мини-футбол, волейбол) төркем этабында яки финалның 1/8 дә фактта катнашуы мәҗбүри булып тора. Алар катнашмаган очракта, команда спорт төре ярышларыннан төшереп калдырыла, ярышлар нәтиҗәләре яңадан карала.

3.3. Спартакиадада түбәндәгеләргә катнашырга рөхсәт ителми:

Спартакиадада катнашучының үзәк аппараты хезмәткәрләре булмаган хезмәткәрләргә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче үзәк аппарат эшчеләре булган хезмәткәрләргә;

Спартакиадада катнашучының территориаль бүлекчәләре хезмәткәрләренә;

Спартакиадада катнашучының ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләренә;

спорт исемнәре бирелгән, Спартакиаданың спорт төре буенча «Россия гроссмейстеры», «Россия спорт мастеры» һәм «халыкара класстагы Россия спорт мастеры» дигән спорт исемнәренә ия хезмәткәрләргә;

Спартакиаданың спорт төре буенча «спорт мастерына кандидат» дигән спорт исеменә ия булган, чираттагы Спартакиаданы үткәрүгә кадәр алдагы өч елдан да соңга калмыйча расланган спорт разряды бирелгән хезмәткәрләргә;

Спартакиаданың спорт төрләре буенча гамәлдәге спортчыларга (спортның индивидуаль һәм команда төрләре буенча Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясе җыелма командалары әгъзаларына);

кимендә алты ай Спартакиадада катнашучысы штатында эшләүче хезмәткәрләргә, түбәндәгеләрдән тыш:

Спартакиадада катнашучының җитәкчеләреннән һәм аларның урынбасарларыннан;

дәүләт хезмәте стажын өзмичә, Татарстан Республикасының башка дәүләт хакимияте органнарыннан, шулай ук командалары узган елгы Спартакиадада катнашкан башкарма хакимият федераль органнарының территориаль органнарыннан эшкә алынган дәүләт хезмәткәрләреннән (әлеге дәүләт хакимияте органнарында кимендә алты айлык гомуми эш стажы белән).»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең ел саен үткәрелә торган Спартакиадасын әзерләү һәм уздыру турындагы нигезләмәнең 2 нче кушымтасында:

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Спартакиада ярышларында 1 төркем һәм 2 төркем командалары арасында бер кешегә иң күбе бер спорт төрендә катнашырга рөхсәт ителә.

3 төркем командалары арасында ярышларда бер кешегә иң күбе ике спорт төрендә катнашырга рөхсәт ителә.

Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына, башлыклары урынбасарларына, башкарма комитетлары җитәкчеләренә, шулай ук спорт идарәләре, бүлекләре һәм секторлары башлыкларына/мөдирләренә Спартакиаданың барлык спорт төрләрендә катнашырга рөхсәт ителә.»;

6.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6. Бадминтон.

Ярышларның характеры – команда характерында.

Команда составы – 4 кеше, шул исәптән 2 ир-ат һәм 2 хатын-кыз.

Ярышлар 2 этапта уздырыла.

1 нче этап: төркемнәрдә һәрберсе бер-берсе белән божра система буенча уеннар.

Уеннар командаларның уенда катнашучыларның һәрберсе арасында үткәрелә (өч уен).

2 нче этап: плей-офф сериясендәге уеннар (финалның 1/8, 1/4, 1/2), 3 нче урын өчен матч, финал.

Финалның 1/8 пары, төркем этабы уеннарын үткәрелгәннән соң, жирәбә салу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

Ярышлар Россия бадминтон федерациясе кагыйдәләре буенча уздырыла.

Һәр команда очрашуы өч очрашудан тора:

1 нче очрашу – парлы (микст);

2 нче очрашу – ялгыз, хатын-кызлар уйный;

3 нче очрашу – ялгыз, ир-атлар уйный (плей-офф сериясендә – кирәк булуга карап).

Микст составына керүче уенда катнашучылар ялгыз очрашуларда катнаша алмый.

2 очко җыйган команда очрашуда җиңүче дип санала.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.9 пункт өстәргә:

«6.9. Бильярд.

Ярышларның характеры – ялгыз характерында.

Команда составы – 1 кеше. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, башлыклары урынбасарларына яки башкарма комитетлары җитәкчеләренә катнашырга рөхсәт ителә.

Ярышлар «Ирекле пирамида» уены кагыйдәләре буенча үткәрелә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры — А.В.Песошин